

Мордовиянен 70 456 (7842-беренче сыйныфка) укучысына 336 белем бирv учреждениеләрен яна 2017-2018 уку елына әзерлек эшләре тулы кочено бара, дип хәбәрли регионыбыз Роспотребнадзоры. Әйтеп китәргә кирәк, 67 мен укучылы 327 мәктәптә дәресләр бер сменада vтәр. Тугыз мәктәпнен 3122 укучысы гына икенче сменада укыр.
Белгечләр әйтvенчә, тvбәндәге шартларны vтәгәч, мәктәп укучыларны кабул итәргә хокуклы: коз-кыш вакытларына ягып жылыту системасы тозекләнгән булса, эчә торган сунын нормаларга туры килvе турында бәяләмә бирелсә, барлык технологик һәм башка жиһазлар эшләсә, бина ремонтлау тәмамланган булса, укыту процессына методик кулланмалар әзер булса. Быелгы уку елына әзерлек һәръяклап тикшерелде. Роспотребнадзор Идарәсе белгеч-ләре 198 мәктәпне тикшергәннәр һәм санитар-эпидемиологик таләпләргә туры килмәгән 173(87,4%) мәктәп барлыгы ачыкланган. Бvгенгә 99% кисәтv буенча тозәтvләр vткән инде.
Мордовия мәктәпләрен яна уку елына әзерлек буенча тикшерvләр дәвам итә.
- 9 август конне Рузаевка районы Татар Пешлә гомуми белем бирv мәктәбебезне 1 сентябрьгә укучыларны кабул итәргә әзерлек буенча тулы тикшерv бер кисәтvсез vтте. Быел беренче сыйныфка 27 укучы кабул итәрбез. Алар бу конне тvземсезлек белән котә. Уку елына әзерлекнен тагы бер моһим мәсьәләсе - укучыларны дәреслекләр белән тәэмин итv. Бvгенге кондә федераль һәм региональ исемлектәге дәреслекләр, мәктәпләр ихтыяжларын исәптә тотып, сатып алынган. Хәзер дәреслекләрне муниципаль берәм-лекләр мәктәпләргә, ә мәктәпләр укучыларга тарату эшен алып бара. Дәреслекләр белән дә бездә кыенлыклар юк, яналарын да укучыларга тулы кvләмдә тараттык инде,- дип белдерде мәктәп директоры Флора Ахметжан кызы Шамонова. - Быел район житәкчеләребез «Устойчивое развитие сельских территорий» программасы кысаларында Татар Пешләсе урта мәктәбе укучыларына зур бvләк ясарга жыеналар: ясалма ябылмалы 42х24 метрлы мини-стадион тозеп бирәчәкләр. Мини-стадионда йогерv юлы һәм тирә-ягы койма белән корылган, прожекторлы, яшелләндерелгән һәм 24 урынлы булачак. Сонгы штрихлары гына калды, уку елы башына зур бvләкне кабул итәргә жыенабыз.
Темник районы Тархан мәктәбендә быел барлыгы 18 укучы белем алачак. Аларнын тугызы кыз бала һәм малайлар да шул ук кvләмдә. 2017-18нче уку елын тулы әзерлек белән каршы алырга жыеналар; тикшерvләр vткән. Әмма бераз кvнелсезрәк - беренче сыйныфка килvче укучылары быел юк, - дип хәбәр итте мәктәп директоры Халисә

Сафиулла кызы Кугушева.
Әмма, унай яклар белән бергә, берникадәр кыенлыклар да бар укучыны мәктәпкә жыюда. Советлар чорында да, бvген дә укучыларга канцтоварлар алу укучынын әти-әнисе жилкәсендә. Ләкин Советлар чорында икеләтә ким кvләмдә сатып алырга кирәк иде һәм бәясе дә кәпикләр торды. Мәсәлән, Саранск шәһәре укучыларына китапларны мәктәп китапханәсеннән тvләvсез оләшәләр, ә башлангыч сыйныфларга эш дәфтәрләре (рабочие тетради) бер икенче сыйныф укучысына гына да якынча 1500-2000 сумга тошә. Дәфтәр-ручкаларга тагы бер мен сумлык тирәләре кирәк. Шулай итеп, Мордовиядә яшәгән әти-әниләргә бу кыйбат сумма; анын остенә формасы, спорт киемнәре, сумкасы һәм башкаларын сатып аласылары бар. Әйтеп китәргә кирәк, 2011 елнын 30 июнендәге Мордовия Главасы Указы нигезендә респуб-ликабызнын кvпбалалы гаиләләрендәге мәк-тәптә укучы һәрбер балага, оч һәм артык балалы ялгыз аналарга, ятим бабаларны тәрбияләvче опекуннар һәм гаиләгә кабул иткәннәргә, I һәм II группа инвалидларны тәрбияләvчеләргә, гаи-ләнен һәрберсенә уртача керемне узмаган табышлыларга һәм башка категориялеләренә, яна уку елына әзерләргә ярдәм йозеннән, 1500 сум исәбеннән материаль ярдәм кvрсәтелеп килә; быел да шулай.
Мәктәпләрдә бердәм форма кертv турындагы мәсьәлә республикабызда 2009 елдан башлап кvтәрелеп килде. Бvгенге кондә белем бирv йортларында укучылар бердәм киемнән йориләр. Чонки хәзер “Мәгариф турында”гы закон шундый таләп куя.
Мәктәп укучысын форма белән тәэмин итәргә республика житештерvчеләренен момкинлеге житәрлек. Нигездә, фаб-рикаларыбыз тәкъдим иткән мәктәп киемнәренен бәясе 1,5-2,5 мен сум тирәсе. Ата-анага, мәктәп житәкчелеге белән бер фикергә килеп, алар арасыннан сайлап алу момкинлеге бирелә. ООО “Узоры Мордовии” белгечләре, Стандартлар таләп иткәнчә, укучыларга мәктәп формасынын 15тән кvп торен уйлап теккәннәр. Кибетләрендә кызларга мәктәпкә кия торган кvлмәк 800 – 1500 сумга кадәр, алъяпкыч – 470-700 сумга кадәр, ак яка – 120-150 сум тора.
Шулай республикабызда яна уку елына әзерләнәләр. Мәктәпләр укучыларын котә.

**Наилә Насырова**